ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Милли спорт төрен үстерү тиешле бөтенроссия спорт федерациясе тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта, мондый милли спорт төре буенча спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары, спорт судьяларының квалификация категорияләре Федераль закон нигезендә бирелә.»;

2) 16 статьяның 2 өлешенә «(тиешле бөтенроссия спорт федерациясе тарафыннан үстерелә торган милли спорт төрләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 15 декабре
№121-ТРЗ